

# Кроссвордны чишегез.

1. Баш хәрефтән язсак Г.Тукайның «Шүрәле» әсәрендәге кушамат, юл хәрефтән язганда – рәвеш.
2. Су ташыганддa – савыт, -ләп кушымчасы ялгагач, рәвеш .
3. Бер өлеше сан, икенчесе – секундлар, минутлар, еллар, гасырлар белән үлчәнә торган яшәеш арасы. Икесе бергә кушкач, рәвеш.
4. 2 зат кушымчасы+и.к. кушымчасы+чә – бу нинди рәвеш
5. «Кыш» сүзенә нинди кушымча  ялгагач, рәвеш килеп чыга?

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | б | ы | л | т | ы | Р | | | | |
| | 2 | | ч | и | л | Ә | к | л | ә | п |
| | | 3 | б | е | р | В | а | к | ы | т |
| | 4 | с | е | з | н | Е | ң | ч | ә | |
| | | | 5 | к | ы | Ш | ы | н | | |


Рәвеш

1. Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем;
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.

2. Шул рәвешчә бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач,
Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс башым.

3.Әйт әле, күбәләк, сөйләшик бергәләп,
Бу кадәр күп очып, армыйсың син ничек?


Эш яки хәлнең билгесен белдерә
Рәвеш


Эш яки
хәлнең
билгесен
белдерә
Сораулары:
Ничек?Күпме?
Кайда?Кайчан?
Ник?
Рәвеш
:

Ребуска ачкыч табып, нәрсә язылганын белегез.

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| г | м | й | з | д | а | ж | е | к | в | и | б | л |
| мор | ләр | тәр | як | фо | Рә | гик | ло | лән | ләр | тан | веш | ми |



Эш яки хәлнең билгесен белдерә
Сораулары: Ничек?Күпме? Кайда?Кайчан? Ник?
Морфологик яктан төрләнми
Рәвеш :

# Рәвеш төркемчәләре

Рәвеш төркемчәләре

**Саф**
Ничек?
Ни рәвешле?

*Кинәт, яланаяк, салмак, җәяү*

**Күләм-чама**
Күпме?
Ничаклы?

*Байтак, аз, күп, көн-төн, бераз*

**Охшату-чагыштыру**
Ничек?
Ни төсле?

*Бүредәй, чишмәдәй, олыларча, кояштай*

**Вакыт**
Кайчан?

*Төнлә, быелтыр, бүген, быел, кышын, соңыннан*

**Урын**
Кая? Кайдан?
Кайда?

*Ерак, монда, түбән, югары*

**Сәбәп-максат**
Ник? Нигә?
Нилектән?

*Юри, тикмәгә, юкка, бушка*

## Ясалышы буенча рәвешләр 5 төргә бүленә:

*Тамыр: аз, бик, еш, сирәк.*
*Ясалма: татарча, кичен.*
*Кушма: көнозын, бераз.*
*Парлы: тора-бара, тиз-тиз.*
*Тезмә: шул арада, тиз арада.*

## Рәвеш ясагыч кушымчалар

| | |
|---|---|
| *-ча // -чә* | *яшьләрчә, заманча;* |
| *-лай // -ләй* | *бушлай, бөтенләй;* |
| *-лата // -ләтә* | *акчалата, икеләтә;* |
| *-дай // -дәй* | *аюдай, җилдәй;* |
| *-тай // -тәй* | *чәчәктәй, коштай;* |
| *-лап //-ләп* | *яхшылап, еллап;* |

**Рәвеш :**

**Эш яки хәлнең билгесен белдерә**

**Сораулары: Ничек?Күпме? Кайда?Кайчан? Ник?**

**Морфологик яктан төрләнми**

**6төркемчәсе бар:**
**Саф**
**Күләм-чама**
**Охшату-чагыштыру**
**Вакыт**
**Урын**
**Сәбәп-максат**

**Ясалышы:**
**Тамыр**
**Ясалма**
**Кушма**
**Парлы**
**Тезмә**

# Рәвешнең дәрәҗәләре



- Рәвешләрнең ясалышы буенча белемнәрегезне перфокарталар ярдәмендә тикшерик

| | тамыр | ясалма | парлы | кушма | тезмә |
|---|---|---|---|---|---|
| көнозын | | | | | |
| шул арада | | | | | |
| акчалата | | | | | |
| тора- бара | | | | | |
| гаять | | | | | |
| олыларча | | | | | |
| тиз | | | | | |
| иртә-кич | | | | | |

1.Рәвеш нәрсәне белдерә?

- предметның билгесен
- эш-хәлнең билгесен

2. Рәвеш нинди сорауларга җавап бирә?

- ничек? күпме? кайчан? кайда?
- нинди? кайсы? ничек? кая?

3. Рәвешләрнең үзләренә генә хас нинди билгесе бар?

- зат-сан белән төрләнә
- төрләнми торган сүз төркеме

4. Төзелеше ягыннан нинди рәвешләр була?

- тамыр, ясалма, парлы
- тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә

5. Бирелгән сүзләр арасында рәвешләрне тап.

- суык, матуррак, алсу, кызгылт
- бераз, шул арада, быел, яхшы

# Йомгаклау.

Эш яки хәлнең билгесен белдереп, ничек? күпме? кайчан? кайда? кая? нигә? сорауларына җавап бирәторган мөстәкыйль сүз төркеме рәвеш дип атала.

Рәвеш күбрәк фигыльгә ияреп килә: ерак бардык, иртәгә кайту, тиз сөйләшү.

Рәвеш эш яки хәлнең үтәлү урынын, вакытын, күләмен,максатын яки сәбәбен, ысулын яки рәвешен белдерә.

*Рәвешнең мәгънә төркемчәләре:*

*1.Саф рәвешләр(тиз,салмак,тын);*

*2. Күләм-чама рәвешләре(күп, байтак, еш-еш);*

*3. Охшату-чагыштыру рәвешләре(кышкыдай, аюдай, кояштай);*

*4. Вакыт рәвешләре (кичә, көзен, күптән);*

*5. Урын рәвешләре (еракта, югарыда, ары);*

*6. Сәбәп-максат рәвешләре (юкка, ачудан, юри);*

- **Рефлексия.** Р.Фәхреддин болай ди:

“Гыйлем –күңел күзен ача. Гыйлем галимнәрнең зиннәте, адәмнәрнең хөрмәте булып, һич бетми торган байлыктыр. Галим яки гыйлем өйрәнүче, яки тыңлаучы, яки гыйлемне сөюче булып йөр! Гыйлем –ул дан күлмәге. Һәрбер фәнне үзләштер, надан булма”

Бу сүзләргә нигезләнеп, дәрескә нәтиҗә ясагыз:

**Чынлап та...**

**Мине иң гаҗәпләндергәне шул булды:**

**Мин аңладым:**

**... минем өчен шунысы кызыклы булды.**

